ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 27.02.2017 г. Казань № 39

Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең кулланучылар өчен үтемле булуын ачыклауда кулланыла торган критерияләр системасын билгеләү турында

"Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында" 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя хасил итү нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик дәрәҗә индексларын җайга салу тәртибе турында" 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, боерык бирәм:

1. Шушы боерык кушымтасына туры китереп, коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең кулланучылар өчен үтемле булуын ачыклау да кулланылучы, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җайга салына торган критерияләр системасын билгеләргә.

2. Үтемле булу критерияләре системасының, коммуналь комплекс оешмаларының җитештерү программаларын килештергәндә һәм шушы оешмаларның хезмәтләренә тарифлар билгеләгәндә, шулай ук аталган оешмаларның эшчәнлек шартлары объектив үзгәртелгән очракта коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренә булган тарифларны вакытыннан алда яңадан караганда, кулланучылар өчен коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең үтемле булуын ачыклау өчен кулланыла дип билгеләргә.

3. Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең кулланучылар өчен үтемле булуын анализлау каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү өчен файдаланыла торган коммуналь инфраструктура системаларын эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы коммуналь комплекс оешмаларына карата гамәлгә ашырыла.

4. Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренә тарифлар коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләреннән файдаланучыларның да, әлеге хезмәтләрнең кулланучылар өчен үтемле булуын тәэмин итүче коммуналь комплекс оешмалары

өчен дә мәнфәгатьләр балансына ирешүне һәм коммуналь комплекс оешмаларының нәтиҗәле вазыйфалавын тәэмин итәргә тиеш.

5. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең кулланучылар өчен үтемле булуын билгеләү өчен кулланыла торган критерияләр системасын билгеләү турында" 2016 елның 12 февралендәге 35 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

6. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

7. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.П. Борисовка йөкләргә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
27.02.2017 № 39 боерыгына кушымта

Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең кулланучылар өчен үтемле булуын ачыклауда кулланылучы, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан җайга салына торган критерияләр системасы

1. Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең физик яктан үтемле булуы. Хезмәтләрнең физик яктан үтемле булу критериясе кулланучылар өчен, коммуналь комплекс оешмаларының җитештерү программаларына туры китереп, таләп ителүче хезмәтләр күләме күрсәтелүнең тәэмин ителешен билгели.

2. Коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренең икътисадый яктан үтемле булуы. Кулланучылар өчен хезмәтләрнең икътисадый яктан үтемле булу критериясе кулланучылар тарафыннан хезмәтләрнең бәяләрен түли алу мөмкинлеген чагылдыра.